ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның «02» декабреннән № 340

**Яңа Чишмә муниципаль районында 2016 елга балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны раслау турында»**

«Мәгариф турында» 2012нче елның 29нчы декабрендәге 273-ФЗ Россия Федерациясе Законының 99 Статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 06нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле һәм күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009нчы елның 31нче декабрендәге 939нчы номерлы карары һәм Яңа Чишмә муниципаль районы уставы нигезендә карар бирәм:

1. 2016 елга түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, табигый-фәнни, техник һәм

культурологик юнәлешле мәгариф программаларын һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем биру оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты.

2. Яңа Чишмә муниципаль районының финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1нче пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1нче пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Расланган
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның «02» декабрендәге
340 номерлы карары белән

**Туристлык-туган якны өйрәнү, экология-иология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар, 1 укучыга, 1 елга, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 4228 | 7829 | 9395 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 4127 | 7642 | 9170 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 4531 | 8391 | 10070 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 4329 | 8017 | 9620 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 4329 | 8017 | 9620 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 4329 | 8017 | 9620 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 3924 | 7267 | 8720 |
| Социаль-икътисади | авыл җирлеге | 3924 | 7267 | 8720 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 4329 | 8017 | 9620 |